Республика Татарстан
Глава Енабердинского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423643, Менделеевский район, д. Енабердино,
ул. Новая, д 10а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге Башлыгы

423643, Менделеевск районы,
Енабердино авылы,
Яна урамы, 10а

тел./факс 8/85549/3-56-29, E-mail: Enbrd.Men@tatar.ru,
http://mendeleevsk.tatarstan.ru/rus/enaberdinskoe-selskoe-poselenie.htm

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

5 ноябрь 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Енабердино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы
КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 15 ноябре 17.00 сәг. ТР, Менделеевск муниципаль районы, Туйма торак пункты, Вахитов ур. 40А й. адресы буенча урнашкан Туйма авыл мәдәният йортында Енабердино авыл җирлегенең Туйма торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. "2025 елда үзара салымны Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Туйма авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, югары уку йортларының һәм урта махсус уку йортларының көндезге бүлеге студентларыннан тыш, 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан салымны 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорауны расларга.

1. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Туйма авылында яктырткычлар сатып алу һәм алыштыру).

2. Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Туйма авылында насос сатып алу).

3. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Туйма авылында юлларны кардан чистарту. Тойма авылында вак таш сатып алу, ташу, тигезләү ).

«ЗА» «ПРОТИВ».

3. « РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Енабердино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Җыенда рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге башлыгы ____________ Е.Ю.Скворцова